# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ДҮРТ-МУНЧА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАРЫ

**25.12.2018 ел** **№15**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Уставы, «Гражданнарның үзара салымы турында» 2014 елның 05 февралендәге 130 номерлы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге башкарма комитеты

**карар итте:**

1. Дүрт-Мунча авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Т. Ситдыйков**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Дүрт-Мунча авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2018 елның 25 декабрендәге
15 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Дүрт-Мунча авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары киләсе календарь елның 15 февраленә кадәр Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан кала, җирле референдумда (җыенда) катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан түләнә.

3. Түләми тору өчен нигезле сәбәпләр булып түбәндәгеләр торырга мөмкин:

а) вакытлыча хезмәткә яраксызлык (6 айдан артык),

б) оешманы бетерү, оешма хезмәткәрләренең санын яки штатын кыскарту сәбәпле эштән азат ителү,

гражданнарга гариза нигезендә түләүне кичектерү ике айдан да артык булмаган вакытка бирелергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (белдерү) бланкы турында гражданнарга хәбәр җирлекнең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру, кул куйдырып, кулга бирү юлы белән җиткерелә, почта элемтәсе аша җибәрелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салым акчалары Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почтадан акча күчерү юлы белән (исәп-хисап оешмалары), Дүрт-Мунча авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының https://uslugi.tatarstan.ru сылтамасы аша башкарыла.

7. Түләү фактын раслый торган документлар булып приход касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

8. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Дүрт-Мунча авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2018 елның 25 декабрендәге
15 номерлы карарына
2 нче кушымта

____________________ авыл җирлеге бюджетына бер тапкыр түләнә торган салымны түләү турында _____ номерлы

ХӘБӘРНАМӘ (БЕЛДЕРҮ)

Түләүченең
Ф.И.А.________________________________________________
Адресы: ______________________________________________
Сезгә ______________________________нигезендә ______________
вакытында кадәр ______________чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр ____________ сум күләмендә түбәндәге реквизитлар буенча салым түләргә кирәк.

Банк БИК ______________________________
Сч. № ___________________________
Алучы Сч. № _________________________________
ИНН ___________________________________
КПП ___________________________________
КБК _____________ ОКАТО _______________

Түләүнең
билгеләнеше______________________________________

Җитәкче _______________ ______________________________
М.У. (имза) (имза тулысынча)

- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү линиясе** - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Белдерү) No ____
__________________________________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
бюджетына үзара салым буенча _______________ суммада бер тапкыр түләү турында
Түләүченең Ф.И.А. ______________________________
Адресы: ______________________________________________
Алынган «__» _______________ 20__ ел________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Өзеп бирелә торган квитанция тутырыла һәм түләүчегә хәбәр шәхсән тапшырылганда төпсә____________авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*